**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**« 30 » июль 2019 ел** **№ 226**

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБУ Уставы турында яңа редакциядә» Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 01.02.2018 ел №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБУ учреждениесе Уставына үзгәреш кертү турында (20.08.2018 ел №173 карар редакциясендә)

ТР Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре 3 нче урта мәктәбе» Уставын Россия Федерациясенең 29.12.2012 №273 – ФЗ «Россия Федерациясендә мәгариф турында» гы Федераль законына туры китерү максатыннан карар бирәм:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБУ Уставы турында яңа редакциядә» Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 01.02.2018 ел №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБУ учреждениесе Уставына (20.08.2018 ел №173 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 10 бүлек өстәргә:

«10. Локаль норматив актларны кабул итү тәртибе

10.1. Учреждение үз эшчәнлеген регламентлаштыручы локаль, локаль норматив актлар (мәгариф һәм тәрбия процессын оештыру, идарә органнары эшчәнлеген оештыру, административ һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеген оештыру, методик эш һәм конкурслар уздыру) кабул итәргә хокуклы, мәсәлән: нигезләмәләр, боерыклар, кагыйдәләр, тәртипләр, инструкцияләр, актлар, карарлар, планнар, графиклар, расписание, шартнамәләр һ. б.

10.2. Учреждениенең локаль актлары, локаль-норматив актлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына әлеге Уставка һәм хезмәт шартнамәсенә каршы килә алмый.

Локаль норматив актлар учреждение директоры боерыгы (коллегиаль органнар фикерләрен исәпкә алып) белән гамәлгә кертелә. Укучылар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) хокукларына кагылышлы локаль норматив актларны кабул иткәндә ата-аналар Советы, педагоглар профсоюзының фикере исәпкә алына.

10.3. Учреждение кирәк булганда гамәлдәге локаль актларны үзгәртергә яки гамәлдән чыгарырга хокуклы.

10.4. Расланганнан соң, локаль норматив акт учреждениенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

10.5. Белем бирү турындагы законнар, хезмәт законнары белән чагыштырганда яки билгеләнгән тәртипне бозып кабул ителгән учреждение укучылары яки хезмәткәрләренең хәлен начарайта торган локаль норматив акт нормалары учреждение тарафыннан кулланылмый һәм юкка чыгарылырга тиеш.».

1.2. 9 һәм 10 бүлекләрне 10 һәм 11 бүлекләр дип санарга.

2. ТР Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре 2нче урта мәктәбе директоры (Мөгтәсимов Р.Г.) гамәлдәге законнар нигезендә, Уставка үзгәрешләр кертергә,дәүләт теркәвенә алырга вәкаләтле.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында»: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет - телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Р. Гыйләҗевка йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Шәмсетдинов

«РАСЛАНГАН»
Азнакай муниципаль районы Башкарма комитеты карары
«____ »___________2019  №______

____________________А.Х.Шәмсетдинов

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ 3 НЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР**

Азнакай шәһәре

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБУ Уставы турында яңа редакциядә» Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 01.02.2018 ел №19 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре 3 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБУ учреждениесе Уставына (20.08.2018 ел №173 карар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 10 бүлек өстәргә:

«10. Локаль норматив актларны кабул итү тәртибе

10.1. Учреждение үз эшчәнлеген регламентлаштыручы локаль, локаль норматив актлар (мәгариф һәм тәрбия процессын оештыру, идарә органнары эшчәнлеген оештыру, административ һәм финанс-хуҗалык эшчәнлеген оештыру, методик эш һәм конкурслар уздыру) кабул итәргә хокуклы, мәсәлән: нигезләмәләр, боерыклар, кагыйдәләр, тәртипләр, инструкцияләр, актлар, карарлар, планнар, графиклар, расписание, шартнамәләр һ. б.

10.2. Учреждениенең локаль актлары, локаль-норматив актлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына әлеге Уставка һәм хезмәт шартнамәсенә каршы килә алмый.

Локаль норматив актлар учреждение директоры боерыгы (коллегиаль органнар фикерләрен исәпкә алып) белән гамәлгә кертелә. Укучылар һәм аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) хокукларына кагылышлы локаль норматив актларны кабул иткәндә ата-аналар Советы, педагоглар профсоюзының фикере исәпкә алына.

10.3. Учреждение кирәк булганда гамәлдәге локаль актларны үзгәртергә яки гамәлдән чыгарырга хокуклы.

10.4. Расланганнан соң, локаль норматив акт учреждениенең рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

10.5. Белем бирү турындагы законнар, хезмәт законнары белән чагыштырганда яки билгеләнгән тәртипне бозып кабул ителгән учреждение укучылары яки хезмәткәрләренең хәлен начарайта торган локаль норматив акт нормалары учреждение тарафыннан кулланылмый һәм юкка чыгарылырга тиеш.».

1.2. 10 һәм 11 бүлекләрне 11 һәм 12 бүлекләр дип санарга.